Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № IV-1**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 28 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 48 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатураларны карап чыккач, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп Хәбибуллин Рашат Хәбриевичны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы Вәлиев Илһам Госман улына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәбибуллин Рашат Хәбриевич белән контракт төзергә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәбибуллина Рашат Хабриевичка 2015 елның 29 октябреннән үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга керешергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев